ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_16_»___05__2025ел №495

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының "Муниципаль
хезмәтләр күрсәтүнең административ
регламентларын раслау турында"гы
15.07.2021 ел, № 542 санлы карарына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»гы 28.02.2022 елның 175 санлы карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы районы прокуратурасының 31.01.2025 ел № 02-08-01-2025/Прдп2-25-20920039 «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 15.07.2021 ел № 542 карары белән расланган спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына» протестына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 15.07.2021 ел, № 542 карары белән расланган спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1.3.4 пунктта «бирелергә мөмкин» сүзләрен «бирелә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Спорт разряды бирү өчен документларны карау срогы аларны теркәгән көннән алып 16 эш көне тәшкил итә.

Спорт разряды бирү турында яисә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итү спорт разряды бирү өчен документларны карау тәмамланган көннән алып 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

1.3. 2.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.1. Квалификация категориясен бирү өчен түбәндәге документларны тапшыру зарур:

күрсәтмә (1 нче кушымта):

- кәгазь чыганактагы документ рәвешендә;

- «Электрон имза турында»гы 06.04.2011 елгы 63-ФЗ санлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада бердәм портал, региональ портал аша мөрәҗәгать иткәндә;

Күрсәтмәгә түбәндәге документлар кушып бирелә:

а) ярышларның баш судьялар коллегиясе рәисе (баш судья) имзалаган, нормаларның, таләпләрнең һәм аларны үтәү шартларының үтәлешен чагылдыра торган беркетмә күчермәсе яисә ярыш беркетмәсеннән өземтә;

б) судьялар коллегиясе рәисе (баш судья) имзалаган судьялар коллегиясе составы һәм квалификациясе турындагы белешмә күчермәсе (халыкара ярышлардан тыш);

в) спортның тиешле төре буенча спорт судьясының халыкара категориясе булуын раслаучы документларның күчермәләре һәм рус теленә таныкланган тәрҗемәсе. Күрсәтелгән документларның күчермәләре спортчы кимендә нормалар, таләпләр һәм шартлар үтәгән ярышларда хөкемдарлык иткән судьялар коллегиясе составына кертелгән спорт судьяларына тапшырыла: тиешле халыкара спорт федерациясенең календарь планына кертелмәгән халыкара ярышлар өчен - 5, калган ярышлар өчен - 3.

Документларны электрон рәвештә тапшырганда нотариусның электрон имзасы белән имзаланган нотариаль таныкланган тәрҗемә бирелә;

г) спортчының физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмага каравын раслаучы документның күчермәсе (региональ спорт федерациясенә дәүләт аккредитациясе гамәлдә булу туктатылган очракта яисә исемлеккә кертелгән физкультура-спорт оешмасы тарафыннан спорт разряды бирү өчен документлар тапшырылган очракта);

д) Россия Федерациясе гражданы паспортының икенче һәм өченче битләренең күчермәләре, шулай ук яшәү урыны турында белешмәләр булган битләрнең күчермәләре, ә ул булмаганда Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклаучы Россия Федерациясе гражданы паспортының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), документны биргән орган, документның гамәлдә булу срогы тәмамлану датасы турында белешмәләр булган битләренең күчермәләре (яшүсмерләр спорт разрядлары). Документларны

электрон формада тапшырганда шәхесне таныклаучы документтан белешмәләр тиешле кырларга интерактив порталь формада кертелә һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып, запрос җибәрү юлы белән тикшереләчәк.

14 яшькә җитмәгән затлар өчен - туу турында таныклыкның күчермәсе. Документларны электрон формада тапшырганда туу турындагы таныклыктан белешмәләр тиешле кырларга интерактив порталь формада кертелә һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып, запрос җибәрү юлы белән тикшереләчәк. Әгәр туу турында таныклык чит телдә бирелгән булса, төп нөсхәсен һәм аның нотариаль расланган тәрҗемәсен күрсәтергә кирәк. Документларны электрон рәвештә тапшырганда нотариусның электрон имзасы белән имзаланган нотариаль таныкланган тәрҗемә бирелә.

Чакырылыш буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр Россия Федерациясе гражданы паспорты битләренең күрсәтелгән күчермәләре урынына хәрби билет күчермәсен тапшырырга мөмкин;

е) спорт разряды бирү өчен спортчы нормаларны, таләпләрне һәм аларны үтәү шартларын үтәгән физкультура чарасы һәм (яисә) спорт ярышы турындагы нигезләмәнең (регламентның) күчермәсе;

ж) ярышларның баш судьялар коллегиясе рәисе (баш судья) тарафыннан имзаланган, тиешле ярышларда катнашкан илләрнең (тиешле халыкара спорт федерациясенең календарь планына кертелмәгән халыкара ярышлар өчен) яисә Россия Федерациясе субъектларының (бөтенроссия һәм төбәкара ярышлар өчен) саны турында белешмәләр булган документның (белешмә, беркетмә) күчермәсе.»;

1.4. 2.7.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча өстәргә:

"9) Россия Спорт министрлыгының 19.12.2022 № 1255 боерыгы белән расланган бердәм Бөтенроссия спорт классификациясе турында нигезләмәне раслау хакындагы нигезләмәнең 50-55 пунктларында һәм 57 пунктында каралган таләпләргә туры килми торган документлар тапшыру.»;

1.5. 2.8.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

а) спорт разряды бирү документларында күрсәтелгән спортчы нәтиҗәсенең ЕВСК кертелгән нормаларга, таләпләргә һәм аларны үтәү шартларына туры килмәве;

б) спортчының спорт ягыннан дисквалификациясе;

в) мондый ярышлар һәм (яисә) физкультура чаралары турында аларны оештыручылар тарафыннан расланган нигезләмәләрдә (регламентларда) билгеләнгән ярышларга һәм (яисә) физкультура чараларына кертү шартларын бозу;

г) спортчы норманы, таләпләрне һәм аларны үтәү шартларын үтәгән ярыш кысаларында уздырылган допинг-контроль нәтиҗәләре буенча кабул ителгән допингка каршы кагыйдәләрне спортчының бозуы турында тиешле допингка каршы оешма карары булу;

д) спорт разряды бирү документларында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрне ачыклау;

е) спорт разряды бирү өчен тәкъдимнәр һәм документлар бирү срокларын бозу.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М. Якупов
2-42-05